Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

28 гыйнвар, 2022 ел № 2

Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең кушымта итеп бирелгән бәясен расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегендә «Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»2021 елның 29 гыйнварының 2 номерлы Пановка авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев

Кушымта № 1
Питрәч муниципаль районы Пановка
авыл җирлеге башкарма комитеты
карары белән расланды
28 гыйнвар, 2022 ел №2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү
буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәет җирләү өчен табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1953,25 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 450,77 |
| 4. Кабер казу һәм күмү | 4560,66 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Кушымта № 2
Питрәч муниципаль районы Пановка
авыл җирлеге башкарма комитеты
карары белән расланды
28 гыйнвар, 2022 ел №2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлегендә
2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча
гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү өчен | 363,08 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1590,17 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 450,77 |
| 4. Кабер казу һәм күмү | 4560,66 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |